ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

«

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2020 г. с. Муслюмово № 549

**«2021 елга «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслау турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елга түбәндәгеләрне расларга:

кушымта итеп бирелә торган «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына, әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Бәдретдинова М.Р.

«Мөслим муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге
башкарма комитеты җитәкчесенең
«_______» _____________ 20___ ел
______ номерлы карары белән
РАСЛАНДЫ

**«Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнары»**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучыга елына сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | Биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Бию сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |